ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 октябрь 2025ел № 8537

«2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәрендә хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту» муниципаль программасын раслау турында

Яр Чаллы шәһәрендә хезмәтне саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын тормышка ашыру максатында, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәрендә хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программа чараларын финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетының «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына тәэмин итәргә: 2026 елга - 40 мең сум, 2027 елга - 40 мең сум, 2028 елга - 40 мең сум.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://nabchelny.ru адресы буенча урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе мөдире Р.К. Шипеевага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 21 октябрендәге
8537 номерлы карарына
кушымта

«2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәрендә хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту» муниципаль программасы

1 бүлек. «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәрендә хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту» муниципаль программасының паспорты

<table>
<tr><td>Программаның исеме</td><td colspan="5">«2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәрендә хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту» муниципаль программасы (алга таба – программа)</td></tr>
<tr><td>Программаны эшләү өчен нигез</td><td colspan="5">Россия Федерациясе Хезмәт кодексы</td></tr>
<tr><td>Программаны төп эшләүчеләр</td><td colspan="5">Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе</td></tr>
<tr><td>Программаны үтәүчеләр</td><td colspan="5">Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе</td></tr>
<tr><td>Программаның максаты</td><td colspan="5">Шәһәр оешмаларында хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td colspan="5">- производство травматизмы дәрәҗәсен, беренче чиратта авыр һәм үлем белән тәмамланган очракларны киметү;<br>- хезмәткәрләргә хезмәт эшчәнлеге барышында сәламәт һәм куркынычсыз хезмәт шартлары тудыру</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">2026–2028 еллар</td></tr>
<tr><td rowspan="7">Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2026 ел (мең сум)</td><td>2027 ел (мең сум)</td><td>2028 ел (мең сум)</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>40,0</td><td>40,0</td><td>40,0</td><td>120,0</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>40,0</td><td>40,0</td><td>40,0</td><td>120,0</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="5">Чараларны тормышка ашыру 2028 елга хезмәтне саклау таләпләрен бозу очраклары санын киметергә һәм производствода бәхетсезлек очраклары санын 39 берәмлеккә кадәр киметергә мөмкинлек бирәчәк (2025 ел - 42)</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе квартал саен һәм һәр ел йомгаклары буенча программаны тормышка ашыруны контрольдә тота. Барлыкка килгән социаль-икътисадый хәлне исәпкә алып, программа чараларын аныклау буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертә. |

2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге дәрәҗәсендә программаны эшләү һәм тормышка ашыру кирәклеген билгеләүче мөһим фактор булып шәһәрдәге эшкә сәләтле халыкның тормыш сыйфатын яхшырту һәм сәламәтлеген саклау өлешендә әлеге проблеманың социаль әһәмияте тора.

2. Халык сәламәтлеген яхшырту һәм үлем санын кимету эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып эшләүче халыкның хезмәтен саклау һәм аның шартларын яхшырту, һөнәри куркынычны профилактикалау һәм кимету буенча чаралар кору, шулай ук эшләүчеләргә диспансеризация һәм профилактик тикшерүләр уткәрү тора.

Бүгенге көндә шәһәр предприятиеләрендә һәм оешмаларында производство травматизмы, хезмәтне саклау эшен оештыру, хезмәткәрләргә куркынычсыз хезмәт шартлары тудыру хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә кискен проблемаларының берсе булып кала.

Муниципаль дәрәҗәдә хезмәтне саклау белән идарә итү системасы — ул хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатында җирле үзидарә органнарының эш бирүчеләр, профсоюзлар һәм хезмәткәрләрнең башка вәкилләре белән килештерелгән эшчәнлеге.

Шәһәрдә шәһәр территориясендә эшчәнлек алып баручы оешмаларда хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау буенча даими мониторинг уткәрелә.

2022-2024 елларда Яр Чаллы шәһәрендә производствода үлем һәм авыр нәтиҗәләргә китергән бәхетсезлек очракларында зыян күрүчеләр динамикасы таблицада күрсәтелгән.

| Ел | Бәхетсезлек очраклары саны | Үлем белән тәмамланган | Авыр очрак |
|---|---|---|---|
| 2022 | 18 | 4 | 14 |
| 2023 | 36 | 9 | 27 |
| 2024 | 40 | 9 | 31 |

3 бүлек. Программаны тормышка ашыру сроклары

3. Программаны тормышка ашыру өч елга исәпләнгән: 2026-2028 еллар.

4 бүлек. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары

4. Программаны тормышка ашыруның арадаш һәм ахыргы нәтиҗәләрен бәяләү өчен нәтиҗәлелекне бәяләүнең түбәндәге индикаторы файдаланыла:

| Индикаторның исеме | Чыганак |
|---|---|
| Бәхетсезлек очракларының саны, берәмлек | Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәт инспекциясе |

## 5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

5. 2026-2028 елларга программаны финанслау күләме 120,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча: 2026 ел – 40,0 мең сум, 2027 ел– 40,0 мең сум, 2028 ел – 40,0 мең сум.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

## 6 бүлек. Программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

6. Программа куелган максатларга ирешүне тәэмин итә торган оештыру, методик, санитар-гигиена, укыту-пропаганда, җитештерү һәм башка чараларның бердәм комплексы буларак формалаштырылган һәм тормышка ашырыла.

7. Программаны эшләгәндә, программа чараларын гамәлгә ашырганда бер үк вакытта социаль нәтиҗәгә ирешүне күздә тотып, аны тормышка ашыру чыгымнарын оптимальләштерүгә аерым игътибар бирелде.

8. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә түбәндәгеләр көтелә:

1) эш бирүчеләрнең күбрәк игътибарын хезмәткәрләр хезмәтен саклау проблемаларына җәлеп итү;

2) шәһәр оешмаларында хезмәтне саклау буенча белгечләр санын арттыру;

3) оешмаларда хезмәтне саклау белән идарә итүгә системалы характер бирү.

9. Хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшыртудан гомуми икътисадый нәтиҗә түбәндәгеләр нәтиҗәсендә күренә:

1) вакытлыча эшкә сәләтсезлек буенча пособиеләр түләүләрен кыскарту нәтиҗәсендә оешмаларның керемнәрен, шулай ук бюджетка салым керемнәрен арттыруда;

2) травматизм һәм авыру сәбәпле эшкә яраклылыкны югалтуга бәйле эш вакытын югалтулар санын киметүдә;

3) производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәргә бәйле авырулардан килгән зыянны каплауга бәйле чыгымнарны киметүдә;

4) хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү нәтиҗәсендә алынган табыш күләмен арттыруда;

5) хезмәт шартларын яхшырту хисабына кадрларның агымын киметүдә.

10. Хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту чараларын гамәлгә ашыручы оешмалар гамәлдәге закон таләпләрен бозган өчен штрафларны киметү хисабына шулай ук икътисадый нәтиҗәгә ирешәләр.

11. Программа үтәлешеннән социаль нәтиҗә производство травматизмын һәм һөнәргә бәйле авыруларны киметүдә, хезмәткәрләрнең хезмәт куркынычсызлыгын һәм социаль якланганлыгын арттыруда күренәчәк.

12. Программаны гамәлгә ашыру халыкның, бигрәк тә эшкә сәләтле яшьтә үлем дәрәҗәсен киметү өчен уңай шартлар тудыра.

7 бүлек. Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чараларын финанслау

| № т/б | Программа чараларының исеме | Программа чараларын башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикатор лары, үлчәү берәмлекләре | Шул исәптән сроклар буенча (мең сум) | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2025 (база) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| Максат – шәһәр оешмаларында хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту | | | | | | | | | | | |
| | Программа нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторы | | | Бәхетсезлек очраклары ның саны, берәмлек | 42 | 41 | 40 | 39 | | | |
| 1 бурыч. Производство травматизмы, беренче чиратта авыр һәм үлемгә китергән травматизм дәрәҗәсен киметү | | | | | | | | | | | |
| 1 | Башкарма комитет каршындагы хезмәтне саклау буенча Координация советы киңәшмәләре үткәрү | Башкарма комитетның граждannар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | 2026-2028 еллар | Үткәрелгән утырышлар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | |
| 2 | Квартал саен хезмәтне саклау һәм аның шартларының торышы турында һәм производство травматизмын анализлау турында доклад әзерләү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | 2026-2028 еллар | Докладлар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Шәһәрнең ведомство карамагындагы белем бирү оешмаларында хезмәтне саклау торышы буенча тикшерү үткәрү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | 2026-2028 еллар | Үткәрелгән тикшерүләр саны, берәмлек | 20 | 20 | 20 | 20 | финанслау таләп ителми | | |
| 4 | Физик культура һәм спорт идарәсе карамагындагы учреждениеләрдә хезмәтне саклау торышы буенча тикшерү үткәрү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | 2026-2028 еллар | Үткәрелгән тикшерүләр саны, берәмлек | 17 | 17 | 17 | 17 | финанслау таләп ителми | | |
| 2 бурыч. Хезмәткәрләргә хезмәт эшчәнлеге процессында сәламәт һәм куркынычсыз хезмәт шартлары тудыру | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| 5 | Шәһәр оешмалары арасында хезмәтне саклау һәм аның шартлары буенча иң яхшы эшләрне оештыруга шәһәр смотр-конкурсы үткәрү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | 2026 -2028 еллар | Конкурста катнашкан предприятиеләр саны, берәмлек | 65 | 67 | 69 | 71 | 30,0 | 30,0 | 30,0 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Хезмәтне саклау буенча басма белешмәлекләр (буклетлар, плакатлар) эшләү, әзерләү соңыннан шәһәр оешмаларына тарату | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | 2026-2028 еллар | Әзерләнгән материаллар саны, данә | 200 | 200 | 200 | 200 | 10.0 | 10,0 | 10,0 |
| 7 | Бөтендөнья хезмәтне саклау көненә багышланган чара үткәрү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | 2026-2028 еллар | Үткәрелгән киңәшмәләр саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| 6 | Шәһәр халкына оешмаларда хезмәтне саклау һәм аның шартларының торышы турында мәгълүмат бирү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмгыятьчелек белән элемтә идарәсе | 2026-2028 еллар | Басылып чыккан мәкаләләр саны | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | |
| | Барлыгы: | | | | | | | | 40,0 | 40,0 | 40,0 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева